**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләргә социаль гарантияләр тәэмин итү максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең (алга таба шулай ук – хезмәткәрләр) акчалата гомуми хезмәт хакына айлык вазыйфаи оклады, тиешле елларын эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә, эшнең катлаулыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү, матди ярдәм, һөнәр үзләштергән, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган хезмәткәрләр вазыйфаларын башкарган өчен гамәлдәге законнар нигезендә өстәмәләр керә;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлегенә техник хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең (алга таба шулай ук – эшчеләр) акчалата гомуми хезмәт хакына айлык тариф ставкасы, компенсация түләүләре, айлык тариф ставкасына эшнең катлаулыгы һәм киеренкелеге өчен айлык өстәмә, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм, матди ярдәм, автомобильләр йөртүчеләргә класслылык өчен айлык өстәмә, һөнәр үзләштергән, хезмәт күрсәтү зонасын

киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган хезмәткәрләр вазыйфаларын башкарган өчен гамәлдәге законнар нигезендә өстәмәләр керә;

хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының территориаль органы җитәкчесе секретаренең 11 163 сум тәшкил иткән вазыйфаи окладына тапкырлап исәпләнелә;

эшчеләрнең айлык тариф ставкасы һәм компенсация түләүләре күләме Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүнең Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы Бердәй тариф челтәре нигезендә исәпләнелә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

1 нче кушымта нигезендә хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын;

2 нче кушымта нигезендә эшчеләр хезмәте өчен түләү разрядлары диапазонын.

3. Хезмәткәрләр өчен түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) түбәндәге күләмнәрдә хезмәткәрләргә тиешле елларын эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәне:

| эш стажы | процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык булганда | 15; |

2) вазыйфаи окладка эшнең катлаулыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә айлык өстәмәне;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләүне;

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләрне (премиянең күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүләр вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә елга бер тапкыр түләнә.

Хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, бер тапкыр бирелә торган түләү аның эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә декабрьдә исәпләнелә һәм түләнә, хезмәткәр эштән киткән очракта – соңгы эш көненә кадәр.

Беренче ел эшләгән хезмәткәргә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә. Эшләгән вакыт дип аның эшкә урнашкан көненнән агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр вакыт исәпләнелә;

6) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды кысаларында матди ярдәм;

7) һөнәр үзләштергән, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган хезмәткәрләр вазыйфаларын башкарган өчен – гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә төп эше буенча айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр күләмдә өстәмә түләүләрне.

4. Эшчеләр өчен түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә нормадан тыш эш көне өчен өстәмә түләүдән тыш айлык тариф ставкасына эшнең катлаулыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр күләмдә айлык өстәмәне;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләрне (премиянең күләме эшченең эшчәнлеге нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премия белән бергә ике айлык тариф ставкасы күләмендә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүләрне;

Эшчегә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, бер тапкыр бирелә торган түләү аның эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә декабрьдә исәпләнелә һәм түләнә, хезмәткәр эштән киткән очракта – соңгы эш көненә кадәр.

Беренче ел эшләгән эшчегә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә. Эшләгән вакыт дип аның эшкә урнашкан көненнән агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр вакыт исәпләнелә;

4) хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә класслылык өчен автомобиль йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасы нигезендә расланган айлык өстәмәне түбәндәге күләмнәрдә:

I класслы машина йөртүчеләргә – айлык тариф ставкасының 25 проценты,

II класслы машина йөртүчеләргә - айлык тариф ставкасының 10 проценты.

5) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды кысаларында матди ярдәм;

6) өстәмә түләүләр:

һөнәр үзләштергән, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган хезмәткәрләр вазыйфаларын башкарган өчен – гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә төп эше буенча айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр күләмдә;

төнлә (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) эшләгән өчен – сәгатьлек тариф ставкасының 35 процентына кадәр күләмдә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен – көнлек тариф ставкасының икеләтелгән күләмендә;

хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә нормадан тыш эш көне өчен – айлык тариф ставкасының 50 процентына кадәр күләмдә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренә һәм эшчеләренә тиешле федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән каралган башка түләүләрне башкарырга.

6. Хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү фондын окладлар түләүгә тотыла торган акча суммасыннан артык формалаштырганда түләү өчен түбәндәге чаралар (елга исәпләнгән 12 вазыйфаи окладтан чыгып) күздә тотыла, дип билгеләргә:

1) тиешле елларын эшләгән өчен айлык өстәмә – вазыйфаи окладның җиде проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен хезмәткәрләргә вазыйфаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - вазыйфаи окладның бер проценты күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләү – вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү һәм матди ярдәм вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә.

7. Эшчеләрнең хезмәте өчен түләү фондын түләүгә тотыла торган акча суммасыннан артык формалаштырганда түләү өчен түбәндәге чаралар (елга исәпләнгән 12 вазыйфаи окладтан чыгып) күздә тотыла, дип билгеләргә:

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә – бер айлык тариф ставкасы күләмендә;

2) автомобиль йөртүчеләргә класслылык өчен, нормадан тыш эш көне өчен айлык өстәмә – тугыз айлык тариф ставкасы күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - өч айлык тариф ставкасы күләмендә;

4) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү – айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премия белән бергә ике айлык тариф ставкасы күләмендә.

8. Хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, шулай ук хезмәткәрләргә һәм эшчеләргә айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына бөтен бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

9. Әлеге Указны кабул итү белән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүнең башка шартлары кулланылмый, дип билгеләргә.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

60 көн эчендә үз норматив хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә.

11. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә:

хезмәткәрләрнең вазыйфалары атамасын әлеге Указның 1 нче кушымтасына туры китерергә;

хезмәткәрләргә түләүләр һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү турында үзләренең элек чыгарылган актларын әлеге Указга туры китерергә.

12. Татарстан Республикасы Президенты указларын 3 нче кушымтада бирелгән исемлек нигезендә үз көчләрен югалткан дип танырга.

13. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 22 март
№ ПУ-240

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «22 » мартындагы
ПУ-240 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының үз көчен югалткан указлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 16 июнендәге ПУ-221 номерлы Указы;

2. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 28 февралендәге ПУ-117 номерлы Указы.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 23 гыйнварындагы ПУ-19 номерлы Указы.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-491 номерлы Указы.

5. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 9 февралендәге ПУ-48 номерлы Указы.

6. «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 3 пункты.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-647 номерлы Указы.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-942 номерлы Указы.

9. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2017 елның 11 августындагы ПУ-669 номерлы Указы.